**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**2022 елның 24 нче июненнән** **№ 55**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 1 апрелендәге номерлы 90-ФЗ номерлы Федераль законына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Песәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең 2016 елның 23 мартындагы 25 номерлы карары белән расланган "Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан муниципаль берәмлектә мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук

муниципаль берәмлекнең керемнәре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәне раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктындагы икенче абзацында "акцияләр" сүзен төшереп калдырырга;

1.2. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасында «акцияләр " сүзен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru сайтында һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә www.mendeleevsk.tatarstan.ru сайтына урнаштырырга.

Песәй авыл җирлеге Советы рәисе В.И. Мөхәммәтгалеев